**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Кара-Елга поселогы гражданнары җыены**

**КАРАРЫ**

**10 апрель, 2024 ел** **№1**

Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Кара-Елга поселогында «Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Кара-Елга поселогында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы Кара-Елга поселогы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 07 апрелендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Кара-Елга поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан, I төркем инвалидларыннан, 18 яшькә кадәр 5 һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз пенсионерлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1200 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Кара Елга поселогы юлларына вак таш салып ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Кара Елга поселогында чишмәне төзү һәм ремонтлау (шартнамә буенча түләү);
- Кара-Елга авылында янгын гидрантлары урнаштыру, янгынга каршы комплектлау материаллары сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машинаны тоту (ягулык-майлау материалларына чыгымнар, транспорт йөртүчене тоту);

2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

урам яктыртуны ясау (Кара Елга поселогында урам яктырту өчен урам яктырткычлары һәм теркәкләр сатып алу һәм урнаштыру; урам яктыртуны көйләү өчен махсус җиһазлар сатып алу);

су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (Кара Елга поселогы артезиан скважиналары өчен тирәннән суырту насосы сатып алу);

җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Кара Елга поселогында чишмәне төзү һәм ремонтлау);

янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Кара-Елга поселогында янгын гидрантлары урнаштыру, янгынга каршы комплектлау материаллары сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машинаны тоту (ягулык-майлау материалларына чыгымнар, транспорт йөртүчене тоту);

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кара-Елга поселогы урамнары юлларын вак таш салып ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

торак пункт территориясен төзекләндерү (Кара Елга поселогында яссы спорт корылмаларын төзү һәм булганнарын ремонтлау; поселок территориясендә үләнне чабу);

каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 67 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 35 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 35 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Кара-Елга поселогында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Кара-Елга поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан, I төркем инвалидларыннан, 18 яшькә кадәр 5 һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз пенсионерлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1200 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Кара Елга поселогы юлларына вак таш салып ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Кара Елга поселогында чишмәне төзү һәм ремонтлау (шартнамә буенча түләү);
- Кара-Елга авылында янгын гидрантлары урнаштыру, янгынга каршы комплектлау материаллары сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машинаны тоту (ягулык-майлау материалларына чыгымнар, транспорт йөртүчене тоту);

2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

урам яктыртуны ясау (Кара Елга поселогында урам яктырту өчен урам яктырткычлары һәм терәкләр сатып алу һәм урнаштыру; урам яктыртуны көйләү өчен махсус җиһазлар сатып алу);

су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (Кара Елга поселогы артезиан скважиналары өчен тирәннән суырту насосы сатып алу);

җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Кара Елга поселогында чишмәне төзү һәм ремонтлау);

янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Кара-Елга поселогында янгын гидрантлары урнаштыру, янгынга каршы комплектлау материаллары сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машинаны тоту (ягулык-майлау материалларына чыгымнар, транспорт йөртүчене тоту);

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кара-Елга поселогы урамнары юлларын вак таш салып ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

торак пункт территориясен төзекләндерү (Кара Елга поселогында яссы спорт корылмаларын төзү һәм булганнарын ремонтлау; поселок территориясендә үләнне чабу);

каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зур Сәрдек авыл җирлеге башлыгы Ф.М. Фәттахов